**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА РАЙОНЫ ТЕРРИТОРИТОРИАЛЬ САЙЛАУКОМИССИЯСЕ**

422000, Татарстан Республикасы, Арча ш., Совет мәйданы, 14
телефон:(84366) 3-00-33,факс: 3-14-33, e-mail: 16T.009@tatar.ru

# КАРАР

14.03.2016 № 17

## 2016 елның 13 мартындаТатарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге территориясендә үткәрелгән җирле референдум нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 70 статьясы, «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 55,56 статьясы нигезендә, тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссияләре беркетмәләренең беренче нөсхәләре күрсәткечләре нигезендә Татарстан Республикасы Арча районы территориаль сайлау комиссиясе **2016 елның 13 мартында** узган җирле референдум нәтиҗәләре турында беркетмә төзеде:

"2016 елда Яңа Кырлай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 300 сум, көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, 75 яшьтән өлкәнрәк кешеләрдән 100 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

| № | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар | тоту өчен акча күләме /сум |
|---|---|---|---|
| 1 | Җирлекнең җирле әһәмияттәге юлларына карата юл эшчәнлеге | - юлларга вак таш салу:<br>Яңа Кырлай авылы,Тукай урамы,29 йорттан 95 йортка кадәр;<br>Яңа Иябаш авылы, Төхвәтуллин ур.<br>Өчиле авылы, Тукай урамы<br>-юллардагы чокырларны ремонтлау<br>Чиканас авылы (Совет ур., Октябрь ур.); | 75500<br>50000<br>16000<br>28000 |
| 2 | Күмү урыннарын карап тоту | -зират коймаларын урнаштыру һәм карап тоту:<br>Иске Юрт авылы<br>Югары Бирәзә авылы<br>Кукчә-Бирәзә авылы | 7500<br>14000<br>5 000 |
| | | Барлыгы: | 196000 |

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча авыл җирлеге башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә".

Референдум нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

референдумда катнашучылар исемлегенә тавыш бирү тәмамлануга 1408 референдумда катнашучы кертелгән;

референдумда катнашучылар саны 1269, бу 90,13 процент тәшкил итә;

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча референдумда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«әйе» позициясе өчен референдумда катнашкан 1211 кеше тавыш бирде, бу 95,43 процент тәшкил итә;

«юк» позициясе өчен референдумда катнашкан 58 кеше тавыш бирде, бу 4,57 процент тәшкил итә.

Арча районы территориаль сайлау комиссиясе карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча районы Яңа Кырлай авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны узган дип танырга, ә референдум нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.

2. Мәсьәлә буенча карар кабул итәргә:

"2016 елда Яңа Кырлай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 300 сум, көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, 75 яшьтән өлкәнрәк кешеләрдән 100 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

| № | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар | тоту өчен акча күләме /сум |
|---|---|---|---|
| 1 | Җирлекнең җирле әһәмияттәге юлларына карата юл эшчәнлеге | - юлларга вак таш салу:<br>Яңа Кырлай авылы,Тукай урамы,29 йорттан 95 йортка кадәр;<br>Яңа Иябаш авылы, Тәхвәтуллин ур.<br>Өчиле авылы, Тукай урамы<br>-юллардагы чокырларны ремонтлау<br>Чиканас авылы (Совет ур., Октябрь ур.); | 75500<br><br>50000<br>16000<br><br>28000 |
| 2 | Күмү урыннарын карап тоту | -зират коймаларын урнаштыру һәм карап тоту:<br>Иске Юрт авылы<br>Югары Бирәзә авылы<br>Күкчә-Бирәзә авылы | <br>7500<br>14000<br>5 000 |
| | | Барлыгы: | 196000 |

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча авыл җирлеге башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә".

3. Җирле референдумның гомуми нәтиҗәләрен Арча муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru).

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Татарстан Республикасы Арча районы
территориаль сайлау комиссиясе рәисе Б.И. Кадыйров

Татарстан Республикасы Арча районы
территориаль сайлау комиссиясе секретаре Л.И. Нурмиева